КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 3 ноябрь г.Казань № 1043

«Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртү тармакларын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында

«Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 2016 елның 21 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртү тармакларын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын (алга таба – Программа) расларга.

2. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгын Программаның дәүләт заказчысы һәм аны тормышка ашыру барышын тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын, ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 26 апрель, 282 нче; 2013 ел, 29 апрель, 294 нче; 2013 ел, 29 июнь, 454 нче; 2013 ел, 19 июль, 507 нче; 2013 ел, 24 октябрь, 789 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1110 нчы; 2014 ел, 15 март, 157 нче; 2014 ел, 14 апрель, 242 нче; 2014 ел, 11 июнь, 405 нче; 2014 ел, 9 июль, 475 нче; 2015 ел, 6 май, 326 нчы; 2015 ел, 16 май, 346 нчы; 2015 ел, 22 июль, 532 нче; 2016 ел, 17 февраль, 101 нче; 2016 ел, 27 апрель, 252 нче; 2016 ел, 12 май, 298 нче; 2016 ел, 10 июнь, 396 нчы; 2016 ел, 12 октябрь, 740 нчы; 2016 ел, 26 декабрь, 989 нчы; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2017 ел, 13 май, 281 нче; 2017 ел, 30 октябрь, 821 нче; 2017 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2017 ел, 21 ноябрь, 895 нче; 2017 ел, 28 ноябрь, 920 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1117 нче; 2018 ел, 11 июнь, 458 нче; 2018 ел, 16 ноябрь, 1002 нче; 2019 ел, 5 март, 156 нчы; 2019 ел, 26 апрель, 344 нче; 2019 ел, 27 июнь, 517 нче; 2019 ел, 13 сентябрь, 830 нчы; 2019 ел, 11 декабрь,

1136 нчы; 2021 ел, 24 май, 362 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), аңа түбәндәге эчтәлекле 39 пунктны өстәп, үзгәреш кертергә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «39. | Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртү тармакларын үстерү | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы предприятиеләре | Сәнәгать предприятиеләренең төп фондларын яңартуда булышлык күрсәтү; инфраструктурадан һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итү; сәнәгать предприятиеләренең финанс механизмнарыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин